| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Красноборского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Красный Бор авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.10.2022 Красный Бор авылы № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Зуево торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный бор авыл җирлеге башлыгы карар чыгарды:

1. 2022 елның 28 октябрендә 11 сәгатькә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Зуево авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыен билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: «2023 елда Красный Бор авыл җирлегенең Зуево торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I, II төркем инвалидлардан, студентлардан, көндезге формада белем алучы затлардан, Россия армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, 500 сум күләмендә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллап, үзара салым чараларын кертүгә сез риза булырсызмы?»:

1. Зуево торак пунктында халыкны су белән тәэмин итү буенча Ремонт, хезмәт күрсәтү, тирәнтен насослар һәм материаллар алу, башка хезмәтләр күрсәтү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Зуево авылы, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәйкәле янындагы мәйданчыкта гражданнар җыены үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Е.А.Яковлева